Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Олы Талкыш  авыл җирлеге Советы
Карары

2019 елның 21 нче августы №39/1

Чистай муниципаль районы Олы Талкыш  авыл җирлеге Советының 2019 елның 23 апрелендәге 34/2 нче номерлы «Муниципаль вазыйфа биләүче затларны һәм муниципаль хезмәткәрләрне пенсиягә чыгу сәбәпле, бер тапкыр акчалата бүләкләү турында"гы
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында"гы 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезенләнеп, Чистай муниципаль районы Олы Талкыш  авыл җирлеге Советы

Карар бирә:

1. Чистай муниципаль районының «Олы Талкыш  авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затка түләү, Чистай муниципаль районы Олы Талкыш  авыл җирлеге Советының «Пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә, муниципаль вазыйфаны биләүче затны һәм пенсиягә чыгу уңаеннан муниципаль хезмәткәрне бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү турында»гы 2019 елның 23 апрелендәге 34/2 нче номерлы карары белән расланган пенсиягә чыгу уңаеннан, бер тапкыр акчалата бүләкләү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2 пунктына кертергә, «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында"гы 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә» сүзләрен («Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч, я вакытыннан алда картлык буенча иминият пенсиясе, яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгәч) сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге халкы күмәк җыела торган урыннарда, игъланнар өчен билгеләнгән стендларда һәм такталарда элеп кую юлы белән халыкка җиткерергә, Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга www.chistopol.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлык, хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Олы Талкыш  авыл җирлеге башлыгы Э.Б.Ильин